МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан шәһәре

11.01.2021 № 4

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 211 номерлы боерыгы белән расланган Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 16 маендагы 395 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 211 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 10 маендагы 206 номерлы, 2020 елның 22 апрелендәге 199 номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Инвестиция һәм инновация эшчәнлеге идарәсенең икътисадый анализ һәм проект идарәсе бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Инвестиция һәм инновация эшчәнлеге идарәсе җитәкчесе Д.Р.Шакировка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
11.01.2021 № 4 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 211 номерлы боерыгы белән расланган Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «юридик затлар» сүзләреннән соң «, шул исәптән чит ил (алга таба – предприятиеләр)» сүзләрен өстәргә;

1.3 пункттагы 1.3.5 пунктчаның икенче абзацында «мәгълүмат стендларында» сүзләреннән соң «һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru/) урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округыы) шәһәр яки авыл җирлегендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон). Гариза стандарт бланкта тутырыла (әлеге Регламентка 1 нче кушымта).»;

2.1 пунктта «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 1872 номерлы ТР Законы) 2 статьясы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы арасында инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү формасын раслау хакында» 2006 елның 24 июлендәге 377 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 377 номерлы карары)»;

2.2 пунктта «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмә;»;

2.3 пунктта «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1872 номерлы ТР Законының 2 статьясы;»;

2.4 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Министрлыкта теркәлгәннән соң 40 көн эчендә күрсәтелә, түбәндәгеләрне дә кертеп:

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын әзерләү (алга таба – ТР МК күрсәтмәсе), аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрү, килешүне имзалау һәм мөрәҗәгать итүчегә бирүнең 15 көнлек вакыты;

ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын килештерү һәм предприятие документлары пакетын карауның 15 көнлек вакыты;

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү һәм дәүләт ярдәме күрсәтү мәсьәләсе буенча материалларны карау һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү турындагы күрсәтмәне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслауның 10 көнлек вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче килгән көнне бирелә»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 7 маендагы 284 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 284 номерлы карары) белән расланган нигезләмәнең 6, 7, 9-12 пунктлары;

2.5 пункта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

1 пунктта «1 нче кушымта» сүзләреннән соң «әлеге» сүзен өстәргә;

12 пунктта «4 нче кушымта» сүзләреннән алда «әлеге Регламентка» сүзләрен өстәргә;

2.6 пункттагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Килешү төзүдән баш тарту турында белдерү (алга таба – баш тарту турында белдерү) түбәндәге нигезләрнең берсе булган очракта әзерләнә:

- тапшырылган документлар бизнес-планнарга карата белдерелгән төп таләпләргә туры килмәгәндә;

- тәкъдим ителгән инвестиция проекты Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән төп бурычларга туры килмәгәндә;

- бизнес-планда каралган чараларның максатка ярашсызлыгы, Татарстан Республикасы икътисады өчен аз нәтиҗәле булуы;

- техник-икътисадый исәпләмәләр гамәлдәге методик документларга туры килмәгәндә.»;

2.12 пунктта «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 пункты»;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә сукырларны озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары»;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары;

3.3 пунктта:

беренче абзацны «эш башкару бүлеге» сүзеннән соң «Министрлыкның» сүзе белән тулыландырырга;

3.3.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.6. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә алынган белешмәләрне һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә тапшырылган документларны исәпкә алып, Бүлек белгече:

ТР Министрлар Кабинетының 284 номерлы карары таләпләренә туры килү-килмәүгә инвестиция проектының бизнес-планына экспертиза үткәрә;

инвестиция проектының бизнес-планына уңай бәяләмә проектын (алга таба – бәяләмә проекты) (әлеге Регламентка 3 нче кушымта) һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе) әзерли яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килешү төзүдән баш тарту турында белдерү проектын (алга таба – баш тарту турында белдерү проекты) әзерли;

уңай бәяләмә проектын һәм ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын яки баш тарту турында белдерү проектын Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә килештерүгә өчен җибәрелгән уңай бәяләмә проекты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проекты яки баш тарту турында белдерү проекты.»;

3.3.8 пунктчанда «министр» сүзләреннән алда «Татарстан Республикасы икътисад» сүзләрен өстәргә;

3.3.9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.9. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары әзерләнгән проектларны килештереп, Татарстан Республикасы Икътисад министрына (алга таба – министр) имзалау өчен җибәрә.»;

3.3.12 пунктчада «ТР Финанс министрлыгы тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта:

3.4.1 пунктчаның икенче абзацында «2 нче кушымта» сүзләреннән алда «әлеге Регламентка» сүзләрен өстәргә;

3.4.2 пунктчаның беренче абзацында «эш башкару бүлеге» сүзеннән алда «Министрлыкның» сүзе белән тулыландырырга;

4.1 пунктта «нигезләмәләр» сүзеннән алда «әлеге» сүзен өстәргә;

4.2 пунктта «нигезләмәләр» сүзеннән алда «әлеге» сүзен өстәргә;

4.3 пунктның дүртенче абзацында «законнар таләпләренә» сүзләреннән алда «әлеге» сүзен өстәргә;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе;

2 нче кушымтада «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымтада 1.5 пунктта «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

(белешмәлек) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар, һәм аны күрсәтүне тикшереп торуны гамәлгә ашыручы органнар һәм вазыйфаи затлар реквизитлары

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Шәһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | 524-91-11 | me.rt@tatar.ru |
| Инвестиция һәм инновация эшчәнлеге идарәсе җитәкчесе Д.Р.Шакиров | 524-91-03 | Shakirov.Dinar@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе Миңнуллин Юлай Рим улы | 524-91-34 | Yulay.Minnullin@tatar.ru |
| Бүлек белгече Ибраһимова Гүзәл Рәфгать кызы | 524-90-24 | Guzel.Ibragimova@tatar.ru |
| Эш башкару бүлеге белгече | 524-91-21 | Kseniya.Egorova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәнәгать бүлеге башлыгы Фәсхиев Герман Николаевич | 264-76-74 | German.Faskhiev@tatar.ru«. |